# ХӘТЕР МӘҢГЕ САКЛАР

Казан шәһәре Совет районы 159 нчы лицейның 8 нче А сыйныфы укучыларының иҗади эше.

Җитәкчесе: татартеле һәм әдәбияты укытучысы Галимуллина Л.Ф.

# Ак чәчәкләр Сезгә, ак җаннар!

- 1941 нче елның 22 нче июне һәм 1945 нче елның 9 нчы мае.
- 1418 көн һәм төн буена фидакарь көрәше сәхифәсе.
- Күпмилләтле илебез фашизмга каршы канкойгыч сугышта җиңеп чыга.
- Мин моның белән чиксез горурланам, шуңа күрә дә рефератымны шул чор темасына

# Муса Җәлил
1906-1944



Татар халкының бөек улы, герой шагыйрь Муса Җәлил (Муса Мостафа улы Җәлилов) 1906 елның 15 февралендә элекке Оренбург губернасы (хәзерге Оренбург өлкәсе Шарлык районы) Мостафа авылында крестьян гаиләсендә алтынчы бала булып дөньяга килә.

Муса алты яшеннән авыл мәктәбенә укырга керә, гаилә шәһәргә күчкәч, укуын «Хөсәения» мәдрәсәсендә дәвам иттерә. Мәдрәсә елларында(1914-1917) матур әдәбият әсәрләрен яратып укый, Тукай, Дәрдмәнд, С.Рәмиев иҗатлары белән якыннан таныша, шулар тәэсирендә үзе дә шигырьләр язып, аларны мәдрәсәдәге кульъязма журналга урнаштыра бара.

# Хатыны-Әминә



# Кызы-Чулпан



# Табигать дөньясы

- Иртәнге таң нурыннан
- Уянды ромашкалар.
- Елмаеп хәл сорашып
- Күзгә-күз караштылар.
- Назлады җил аларны,
- Тибрәтеп ак чукларын,
- Таң сипте өсләренә
- Хуш исле саф чыкларын.



# Бәхетле балачак



- Үтеп барам шулай урам буйлап
- Парадныйда күрәм бер бала
- Звонокка үрелә, буе җитми
- Аптырагач, карап уйлана.
- Мин балага киләм:
- -Әллә ,- димен,-
- Звонокка буең җитмиме?
- -Җитми шул,-ди
- -Кая үзем басыйм, Бернеме , -дим, әллә икеме?
- Биш. -.Басам.
- Шуннан бала әйтә:-Абзыкай ,син нинди йөрәкле!
- Әйдә качыйк хәзер, хуҗа чыкса,
- Икебезгә дә бирер кирәкне!

# Хезмәт шатлыгы

- Бик уңган безнең бакчачы бабай,
- Яше үзенең туксанда бугай.
- Ул кояш белән бергә кузгала,
- Көрәген ала, җиңен сызгана.
- Түтәлләр казый, гөлләр утырта,
- Алмагачларның башларын кырка.
- Түтәлне тутырып ,үсә җиләкләр.
- Нәркис.миләүшә.сөмбел һәм мәкләр.



# Моабит дәфтәрләре



# Аның исеме-мәңгелек.



# Татарлар елмаеп үләләр.

- БерлиндагыБерлиндагы Плетцензее төрмәсендә
- 1944нче елның1944нче елның 25 нче августында җәлилчеләрне соңгы юлга – палач балтасы астына алып баралар. Конвоирларның котын алып, төрмә камераларында газап чигүче тоткыннарның күңелендә яшәүгә өмет уятып, үлем аша үлемсезлеккә илтүче 114 адымны (камерадан гильотинога кадәр шул чаклы адым) җырлап үткәннәр, башлары киселгәндә дә елмаеп

# Җәлил һәм җәлилчеләр



- Җәлилчеләр 1944 елның 25 автустында 12 сәг. 06 мин. тан 12 сәг. 36 мин. ка кадәр Берлиндагы Плетцензе төрмә-сендә гильотинада җәзалап үтереләләр.

Изге уйлар, таудай теләкләр күп,
Сулыйсы иде Ватан һавасын!
Дәвам итеп мәңге, кылганнарыбыз
Бер матур җыр булып яңгырасын!

- Әйе, фашизм палачларының дәһшәтле балтасын гаделлек кылычына тиң булган корыч каләме белән җиңгән баһадир җырчыларның шигырьләре, батырлыклары бөтен дөньяда яшәү тантанасы булып яңгырый һәм яңгыраячак!!!

# БерлиндагыБерлиндагы Плетцензее төрмәсендәБерлиндагы Плетцензее төрмәсендә һәлак булган Муса Җәлил һәм аның ун көрәштәше

- Гайнан Кормаш -12 сәгать 06 минут
- Фоат Сәйфелмөлеков- 12 сәгать 09 минут
- Абдулла Алиш-12 сәгать 12 минут
- Фоат Булатов- 12 сәгать 15 минут
- Муса Җәлил -12 сәгать 18 минут
- Гариф Шабаев-12 сәгать 21 минут
- Әхмәт Симаев-12 сәгать 24 минут
- Абдулла Баттал -12 сәгать 27 минут
- Зиннәт Хәсәнов - 12 сәгать 30 минут
- Әхәт Атнашев - 12 сәгать 33 минут
- Сәлим Бохаров - 12 сәгать 36 минут

# Гайнан Кормаш

Син – халыкның батыр
улы,
Исемең мәңге онтылмас:
Һәрчак безнең йөрәктә
син -
Гайнан абый Кормаш!



# Фоат Сәйфелмөлеков



Исемнәре мәңге балкый
Якты йолдызлар кебек.
Кыю иптәш һәм көрәштәш –
Фәрит абый Сәйфелмөлек.

# Абдулла Алиш

Муса абый ялгыз түгел,-
Иптәшләре бар ич:
Бер иптәше - әкиятче
Абдулла Алиш!



# Фоат Булатов



Көннәр матур, ак кар ява,
Күңелдә дәрт уятып...
Тынычлык өчен көрәшкән
Фоат абый Булатов!

# Муса Җәлил

Җыр өйрәткән аны хөр яшәргә
Һәм үләргә кыю ир булып.
Гомре аның моңлы бер җыр иде,
Үлеме дә яңгырый җыр булып.



# Гариф Шабаеф



Кайчандыр безнең шикелле
Булгандыр ул бер сабый...
Һәрчак безнең күңелдә син-
Шабаев Гариф абый!

# Әхмәт Симай

Язмыш кайчак бик
аяусыз-
Төрле яклап сыный
Сынатмадың, халкым
улы-
Әхмәт абый Симай!



# Абдулла Баттал



Батырларны барлыйм, дисәң,
Тарих дәфтәрләрен актар:
Шундый батырларның берсе –
Абдулла абый Баттал!

# Зиннәт Хәсәнов

Батырлар турында һәр көн
Шигырьләр, җырлар туа...
Җыр булып яши күңелдә
Хәсәнов Зиннәтулла!



# Әхәт Атнашев



Дошманнарга каршы батырлар
Көрәшкәннәр берләшеп.
Ул батырларның берсе син-
Әхәт абый Атнашев!

# Галләнур Бохараев

Ил – Ватанга ант итә
Газиз халкым уллары...
Антыңа тугры калдың син-
Сәлим абый Бохаров!



# Җәлилчеләргә Казанның 1нче май мәйданында монумент



# Муса Җәлил исемендәге опера һәм балет театры



# Музей



# Исәннәрнең кадерен бел,
# Үлгәннәрнең-каберен бел!

